ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 октябрь 2021 ел № 6434

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5760 номерлы, 2020 елның 17 августындагы 3995 номерлы, 2021 елның 15 июнендәге 4013 номерлы, 2021 елның 1 сентябрендәге 5766 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Нигезләмәнең 11 пунктында билгеләнгән срок дәвамында объект аның хуҗасы тарафыннан ирекле рәвештә демонтажланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи заты бер эш көне эчендә тикшерү актын, объектны урнаштыруның законсыз булу фактын раслаучы документларны һәм күрсәтмәне кабул итеп алу, урнаштыру фактларын раслаучы документларны (башка дәлилләрне), шулай ук әлеге нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә, күрсәтмә үтәлмәү турындагы актны теркәп, әлеге нигезләмәгә 9 нчы кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау һәм (яки) күчерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли һәм аны билгеләнгән тәртиптә раслый.»;

2) 37, 38 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37. Нигезләмәнең 36 пунктында билгеләнгән срок эчендә күчмә сәүдә

объекты мондый объектның хуҗасы тарафыннан ирекле рәвештә күчерелмәсә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары бер эш көне эчендә, әлеге нигезләмәгә 10 нчы кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыралар һәм аны билгеләнгән тәртиптә килештерәләр.

38. Законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында Башкарма комитет карары имзаланган һәм теркәлгән көнне район хакимиятенең вазыйфаи затлары мондый объектны махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчерү буенча эш башлыйлар.»;

3) Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә, 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча, 9 нчы, 10 нчы кушымталар өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыклары И.Н. Галимовка, В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 1 октябрендәге
6434 номерлы карарына
1 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган
законсыз урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм
саклау тәртибе турында нигезләмәгә
9 нчы кушымта

Законсыз урнаштырылган
объектны демонтажлау һәм (яки)
күчерү турында карар формасы

Законсыз урнаштырылган объектны
демонтажлау һәм (яки) күчерү турында

Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында күрсәтмә үтәлмәү хакындагы актны карап тикшергәннән соң, Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның ______________________ районы хакимиятендә төзелгән демонтажлау комиссиясенә, кушымтада каралганча капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау (күчерү) буенча эшләр оештыруны тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитетның
________________ районы
хакимияте Башлыгы — Ф.И.А.и.

Башкарма комитетның
20__ елның «___» ___________
____ номерлы карарына
кушымта

Демонтажланырга (күчерелергә) тиешле
законсыз урнаштырылган объектлар
исемлеге

| №<br>т/б | Демонтажланырга тиешле объект | Объектның урнашу урыны | Объектны демонтажлау нигезләре | Объектны күчерү урыны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 1 октябрендәге
6434 номерлы карарына
2 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган
законсыз урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм
саклау тәртибе турында нигезләмәгә
10 нчы кушымта

Законсыз урнаштырылган
күчмә сәүдә объектын күчерү
турында карар формасы

Законсыз урнаштырылган
күчмә сәүдә объектын
күчерү турында

Законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында күрсәтмә үтәлмәү хакындагы актны карап тикшергәннән соң, Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның ____________________ районы хакимиятендә төзелгән _____________ комиссиясенә, кушымтада каралганча законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү буенча эшләр оештыруны тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитетның
________________ районы
хакимияте Башлыгы — Ф.И.А.и.

Башкарма комитетның
20__ елның «___» ___________
____ номерлы карарына
кушымта

Кучерелергә тиешле
законсыз урнаштырылган
күчмә сәүдә объектларының
исемлеге

| №<br>т/б | Күчерелергә тиешле күчмә сәүдә объекты | Күчмә сәүдә объектының урнашу адресы | Күчмә сәүдә объектын күчерү өчен нигезләр | Күчмә сәүдә объектын күчерү урыны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева